**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ВАРЯШ-БАШСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МУСЛЮМОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ВӘРӘШБАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**КАРАР**

*423979 РТ Муслюмовский район,с.Варяш-Баш, ул.Кооперативная д 31а*

Vbash.Mus@tatar.ru тел.8(8-5556)3-07-20

ИНН 1629003985, КПП 162901001, ОГРН 1061687005214, ОКАТО 92242817000

№ 2 Вәрәшбаш авылы “20” февраль 2019 ел

**Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Вәрәшбаш авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә хезмәт күрсәтү бәяләрен раслау турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Җирләү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында күмү һәм җирләү эше турында» Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары, «2019 елда түләүләрне, пособиеләрне һәм компенсацияләрне индексацияләү күләмен раслау турында" Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2019 елның 24 гыйнвары 32 номерлы карары нигезендә Мөслим муниципаль районы Вәрәшбаш авыл җирлеге Башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. 2019 елның 1 февраленнән Мөслим муниципаль районы Вәрәшбаш авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен 5946,47 сум күләмендә билгеләргә һәм 1нче Кушымта һәм 2нче Кушымта нигезендә гамәлгә кертергә.
2. Әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Вәрәшбаш авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

**Башкарма комитет итәкчесе** **З.М.Маннапова**

Мөслим муниципаль районы
Вәрәшбаш авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесенең
20.02.2019 ел, 2 нче санлы
карарына 1нче кушымта

Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы
Вәрәшбаш авыл җирлегендә
2019 елның 1 февраленнән җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге

| **Хезмәт күрсәтү исеме** | **Хезмәт күрсәтү бәясе (*сум.*)** |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0,00 |
| 2. Табут китерү, җирләү өчен кирәкле әйберләр белән тәэмин итү | 3263,44 |
| 3. Үлгән кешенең мәетен (җәсәдләрен) зиратка китерү | 943 |
| 4. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 1740,03 |
| **Барлыгы** | **5946,47** |

Мөслим муниципаль районы
Вәрәшбаш авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесенең
20.02.2019 ел, 2 нче санлы
карарына 2 нче кушымта

Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы
Вәрәшбаш авыл җирлегендә
2019 елның 1 февраленнән җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге

| **Хезмәт күрсәтү исеме** | **Хезмәт күрсәтү бәясе (*сум.*)** |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0,00 |
| 2. Кәфенләү | 891,85 |
| 3. Табут китерү, җирләү өчен кирәкле әйберләр белән тәэмин итү | 2371,6 |
| 4. Үлгән кешенең мәетен (җәсәдләрен) зиратка китерү | 943 |
| 5. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 1740,02 |
| **Барлыгы** | **5946,47** |